# Иярчен шарт һәм кире җөмләләр.

# ИЯРЧЕН ШАРТ ҖӨМЛӘ

## Синтетик төре

| Бәйләүче чара | Мисаллар |
|---|---|
| 1. Шарт фигыль формасы: -са/-сә | Гөлләр бөреләрен ача, Зәйтүнә кулы тисә. *(Ф. Яруллин)* |
| 2. Сорау кушымчасы: -мы/-ме | Безнең авылның кояшы кичкырын Бишна урманы өстенә төшә башладымы, көннең иң ягымлы вакыты җиткән була. *(Г. Бәширов)* |
| 3. Ияртүче теркәгеч: әгәр (әгәр дә, әгәр дә мәгәр, әгәренки) + -са/-сә шарт фигыль формасы яки икән бәйлек сүзе | Әгәр ул исән булса, Клара, бу үләнне алып кайтып, аңа иснәткән булыр иде. *(Ә. Еники)*<br>Әгәр ул Нуриәсмага яшәү турында менә хәзер хәбәр сала икән, бәлкем, ул аягына да басар. *(Ф. Садриев)* |
| 4. Бәйлек сүз: исә, икән | Төннәр үтте исә, таң ата. *(И. Иксанова)*<br>Шул омтылыш үлә икән, яшәп торуның кирәге дә калмый. *(Р. Сибат)* |

**ИЯРЧЕН ШАРТ ҖӨМЛӘ**

**АНАЛИТИК ТӨРЕ**

**Иярчен шарт җөмлә я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән шарт хәлен ачыклый, я баш җөмләнең шарт хәле урынында килә.** **Нишләсә? Ни булса? Нинди шартларда**

| Бәйләүче чара | Мисаллар |
|---|---|
| Ялгызак **мөнәсәбәтле** сүз: шулай булса, шулай итсә, алайса, юкса, югыйсә һ. б**.** | Арамыздан китәрелсен яман эшләр, Шулай булса алга китәр тәмам эшләр. *(Г. Тукай)* Мөхәммәт, сабырлыкка өндәгәндә дә сабыр булырга кирәген чамалап, сүзне ярты юлда өзде, югыйсә сүз ташкыны әллә кайларга кереп китәчәк иде. *(Я. Зәнкиев)* |

# ИЯРЧЕН КИРЕ ҖӨМЛӘ

## Синтетик төре

| Бәйләүче чара | Мисаллар |
|---|---|
| 1. Шарт фигыль формасы: -са/ -сә + да, дә кисәкчәсе | Өе тар булса да, күңеле киң Җаббарның. (Ә. *Фәйзи)* |
| 2. Хәл фигыль формасы: ***-тач/*** -гәч, -кач /-кәч + та, тә кисәкчәсе | Мәктәп балаларына ял булгач та, әнкәй белән әткәйгә бу кагылмый. *(Н. Әхмәдиев)* |
| 3. Ияртүче теркәгеч: гәрчә + -са/ -сә шарт фигыль формасы + да, дә кисәкчәсе | Гәрчә Баязит абый эчкерсез киңәшчем, риясыз остазым булса да, мин аны да оныттым. *(А. Гыйләҗев)* |
| 4. Бәйлек сүз: карамастан | Дәртле музыка уйнап торуга карамастан, күңелгә кереп оялаган ямансулык хисе |

# ИЯРЧЕН КИРЕ ҖӨМЛӘ

**Иярчен кире җөмлә я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән кире хәлне ачыклый, я баш җөмләнең кире хәле урынында килә.**

## Аналитик төре

| **Бәйләүче чара** | **Мисаллар** |
|---|---|
| Ялгызак мөнәсәбәтле сүз: шулай да, алай да, шулай булса да, шуңа карамастан | Бу хәл Маһруй апаны бик җәберсетте, шулай да ул зарланып йөрмәде.<br>(Г. *Әпсәләмов)*<br>Кызны танымады Госман, алай да йөрәк тирәсендә нидер сулкылдап алды.<br>(И. *Салахов)*<br>Вәзир Исхакны шәех Игәнәй яратмады, шуңа карамастан ул аны хөрмәт итте.<br>*(М. Хәбибуллин)* |

## Җөмләләргә анализ ясарга.

1. Көннәр яхшырырга охшаган, шулай булса без чаңгы шуарга чыгар идек. ( ), [шулай булса]
2. Телебезне сакларга кирәк, югыйсә ул югалырга мөмкин.

( ), [югыйсә]

3. Тырышып укымыйсың икән, чиреккә яхшы билгеләр чыкмый. (икән), [ ]

4. Илең турында уйласаң, гомерең озын була. (...саң), [ ]

5. Ул китте исә, Нәсимә көнләшә... 

1. Баш сау булса, бүрек табыла.
2. Яз килсә, ул киенә, көз килсә, ул чишенә.
3. Куян тозакны онытса да, тозак куянны онытмый (кире).
4. Алты яшәр юлдан кайтса, алтмыш яшәр хәл белер.
5. Кунак килсә, ит пешә,
   Ит пешмәсә, бит пешә.
6. Тал бөресе, тал бөресе,
   Тал бөресен өзмәгез;
   Мин югалсам, я утларда,
   Я суларда эзләгез.
7. Агыйденең аръягында
   Атлар килә адымлап;
   Кайгы кара күлмәк булса
   Юар идем сабынлап.

| Җөмләләр | Җөмлә төрләре |
|---|---|
| 1.Миннән сиңа теләк шул: ил мактарлык үрнәк бул | 1. Иярчен ия җөмлә |
| 2.Кем алдый, шул урлый | 2. Иярчен хәбәр җөмлә |
| 3.Нәрсәгә өйрәнсәң, шуны куарсың | 3. Иярчен аергыч җөмлә |
| 4.Кайчан әти-әниеңә яхшылык һәм игелек кыласың, шулчакта үзеңдә ниндидер илаһи бер көч һәм рәхәтлек таясың | 4. Иярчен тәмамлык җөмлә |
| 5. Хатыңны мин танырлык итеп яз | 5. Иярчен вакыт җөмлә |
| 6. Мәктәп ярышта беренчелекне алырга тиеш, моның өчен без армый-талмый укырбыз | 6. Иярчен урын җөмлә |
| 7. Яраларым төзәлеп бетмәгәнгә күрә, шушы авылда бер атна ятарга туры килде. | 7. Иярчен шарт җөмлә |
| 8. Кайда хезмәт, шунда хөрмәт. | 8. Иярчен күләм җөмлә |
| 9. Без шәһәрдә сез торган кадәр булдык | 9. Иярчен кире җөмлә |
| 10.Сарай тулы халык: картлар, яшьләр, йөзе җыерчыклы балалар | 10. Иярчен максат җөмлә |
| | 11. Иярчен рәвеш җөмлә |
| | 12. Иярчен сәбәп җөмлә |

**Җаваплар: 1ж – 2; 2-1; 3-4; 4-5; 5-11;6-10; 7-12; 8-6; 9-8; 10-3.**

**Бер якта – җөмләләр, икенче якта шул җөмләләрнең схемалары бирелгән. Дөрес җавапны табып язарга кирәк.**

| | |
|---|---|
| **1. Мине сөйсәң, онып туганыңны** | **. (...-сам да), [ ]** |
| **2. Егылсам да, антым хәтеремдә һәркайчан.** | **(...-са да), [ ]** |
| **3. Яратмаса, кыен түгел, төзәтү бу хатаны** | **(...-саң), [ ]** |
| **4. Безне язмыш аерса да, дуслыкны, бәгърем, онытма.** | **(...-сак та...), [ ] .** |
| **5. Кайтмасак та яныгызга, сез безнең йөрәкләрдә** | **(...-са), [ ]** |

**Җавап: 1-3, 2-1, 3-5, 4-2, 5-4**

Халык җырларыннан икешәр юл тәкъдим ителә. Ләкин аларда иярчен шарт җөмлә урыны буш, шул җөмләләрне дөрес табып урнаштырыгыз.

**1. Бас, кызым, Әпипә,**
**......................, мин басам**
**2. Басып сайрар ...............**
**Сандугач та моңлана.**
**3. ................, айга карыйм,**
**Син кара йолдызларга.**

**Талы сынса**

**Син басмасаң**

**Мин сагынсам**

**1. Нинди җөмләләргә иярченле кушма җөмлә диләр?**

А) үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмләгә;

Б) гади җөмләләре интонация ярдәмендә бәйләнгән кушма җөмләгә;

В) гади җөмләләре тезүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнгән кушма җөмләгә;

Г) үзара иярту юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмләгә.

**2. Иярчен җөмлә -**

А) иярченле кушма җөмләнең беренче җөмләсе;

Б) иярченле кушма җөмләнең соңгы җөмләсе;

В) ияреп килгән һәм баш җөмләдән чыгып куелган сорауга җавап булып килгән җөмлә;

Г) иярченле кушма җөмләнең баш җөмләсе.

3.**Баш җөмлә -**

А) теркәгечле тезмә кушма җөмләнең беренче җөмләсе;

Б) ирченле кушма җөмләнең беренче җөмләсе;

В) санау интонациясе белән бәйләнгән җөмләләрнең берсе;

Г) ияртеп килә торган һәм аннан чыгып, башка җөмләләргә сорау куела торган җөмлә.

4.**Баш һәм ирчен җөмләләрне ничек билгелиләр?**

А) иярченле кушма җөмләдә урнашу тәртибенә карап;

Б) сорау куеп;

В) интонациягә карап;

Г) каршы куючы теркәгечләргә карап билгелиләр.

5. **Төзелеше буенча иярчен җөмләләрнең нинди төрләре була?**

А) теркәгечле тезмә кушма;

Б) синтетик;

В) аналитик һәм синтетик;

Г) бүлүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнгән.

**6. Аналитик иярченле кушма җөмләләрдә нинди тыныш билгеләре куела?**

А) өтер;

Б) куелмый;

В) ике нокта, өтер;

Г) өтер, нокталы өтер.

**7. Нинди иярчен җөмлә синтетик дип атала?**

А) баш җөмләгә үзенең хәбәре составында тормый торган чаралар ярдәмендә ияргән җөмлә;

Б) баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә бәйләнгән җөмлә;

В) баш җөмләгә үзенең хәбәре составындагы чаралар ярдәмендә ияргән җөмлә;

Г) баш җөмләгә көттерү интонациясе ярдәмендә ияргән җөмлә.

**Җөмләләрнең схемаларын төзегез.**

1). Фил күтәрмәгәнне, тел күтәрә.

2). Кемнең телендә ни булса, күңелендә шул була.

3). Яшьлегең тырыш булса, картлыгың тыныч була.

4). Яхшы үгет кермәсә, яман үгет керер.

5). Төбе күренмәгән чиләктән су эчмә.

6). Без кабызган утлар сүнмәс алар.

7). Белеме күп укучы һәрчак алдынгы була.

8). Кем тырыша, аны һәрчак хөрмәт итәләр.

9). Мин беләм: сез үзегезне генә кайгырта торган кеше түгел.

10). Без печәнне сез өйрәткәнчә өйдек.

11) Кайда ныклы тәртип урнаштырыла, шунда эш яхшы сыйфатлы итеп башкарыла.

12). Сез бу хатны минем укыганда, бик күп еллар узган булырлар.

13). Җир ап-ак булган, әйтерсең аңа ак юрган ябылган.

14). Без китәсе автобус никтер соңга калып килде.

15). Һәркемгә мәгълүм ки, илне хуҗасызлык тарката.